КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2023 ел, 29 май г.Казань № 653

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтүче «Чистай психоневрология интернаты» дәүләт автоном учреждениесен төзү турында» 2007 ел, 30 июль, 348 нче карарына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама муниципаль районындагы «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен оештыру турында» 2012 ел, 27 ноябрь, 1027 нче карары үз көчен югалткан дип тану хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Социаль хезмәт күрсәтүче «Чистай психоневрология интернаты» дәүләт автоном учреждениесен төзү турында» 2007 ел, 30 июль, 348 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2012 ел, 20 февраль, 131нче карары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

2 пунктның бишенче абзацы үз көчен югалткан дип танырга;

4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт биреме үтәлешен финанслар белән тәэмин итү Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Дәүләт учреждениеләренә карата дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә (эшләр башкаруга) дәүләт йөкләмәсен формалаштыру һәм дәүләт йөкләмәсе үтәлешен финанслар белән тәэмин итү тәртибе турында» 2015 ел, 31 декабрь, 1044 нче карары белән билгеләнгән тәртиптә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары белән ел саен

раслана торган стационар формада социаль хезмәт күрсәтү буенча дәүләт хезмәтләре күрсәтүгә норматив чыгымнардан чыгып гамәлгә ашырыла дип билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Түбән Кама муниципаль районындагы «Веста» гаиләгә һәм балаларга социаль ярдәм күрсәтү территориаль үзәге» дәүләт автоном социаль хезмәт күрсәтү учреждениесен оештыру турында» 2012 ел, 27 ноябрь, 1027 нче карары үз көчен югалткан дип танырга.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин